СОВЕТ ВЕРХНЕУСЛОНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

Ул. Чехова, д.18, с. Верхний Услон, 422570

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЮГАРЫ ОСЛАН МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ СОВЕТЫ

Чехов ур., 18 нче йорт, Югары ослан авылы, 422570

Тел.: (84379) 2-13-38, факс: (84379) 2-18-39. E-mail: sovet.uslon@tatar.ru, verhniy-uslon.tatarstan.ru


РЕШЕНИЕ | КАРАР

30.09.2019 с. Верхний Услон № 49-567

**Югары Ослан муниципаль районы авыл җирлекләре территориясендә су белән тәэмин итү системаларын лицензияләү турында**

Югары Ослан муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең Төзелеш, торак-коммуналь хуҗалык, элемтә һәм энергетика буенча беренче урынбасары Р. Г. Монасиповның «Югары Ослан муниципаль районы авыл җирлекләре территориясендә су белән тәэмин итү системаларын лицензияләү турында» мәгълүматын тыңлаганнан соң,

**Югары Ослан муниципаль районы**
**Карар чыгарды:**

1. Югары Ослан муниципаль районы авыл җирлекләре территориясендә су белән тәэмин итү системаларын лицензияләү турында мәгълүматны игътибарга алырга.

2. Югары Ослан муниципаль районы Башкарма комитетына:

- авыл җирлекләренә су алгычларын норматив хәлгә китерү өчен өстәмә финанс чаралары бүлеп бирү мәсьәләсен карарга, шул исәптән федераль һәм республика программалары чараларын тормышка ашыру аша да;
- су алу җайланмаларын норматив таләпләргә кадәр җиткерү, документларны рәсмиләштерү, скважиналарга лицензия бирү графигына алга таба төзәтмәләр кертү өчен Татарстан Республикасы экология һәм табигый байлыклар Министрлыгына акчаларга ихтыяҗны юнәлтергә.

3. Авыл җирлекләре Башлыкларына су белән тәэмин итү системаларын норматив хәлгә китерү, су белән тәэмин итү объектларын эксплуатациягә тапшыру, әлеге эшчәнлек төрен лицензияләү һәм тарифларны раслау буенча эшне активлаштырырга тәкъдим итәргә.

4. Бу карарның үтәлешен тикшереп торуны Югары Ослан муниципаль районы Советының законлылык, хокук тәртибе һәм регламент буенча даими комиссиясенә йөкләргә.

**Совет Рәисе,**
**Югары Ослан муниципаль районы**
**Башлыгы** **М.Г. Зиатдинов**